| | |
|---|---|
| ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3.03.2023 г.Лениногорск № 119

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 27 октябрендәге 17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 27 сентябрендәге 163 номерлы редакциядә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәр муниципаль берәмлеге Советы карарына (2018 елның 27 сентябрендәге 163 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 0,1 проценты түбәндәгеләргә мөнәсәбәттә:

- гаражлар һәм машина урыны;
- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалар;
- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә, күчемсез мөлкәт объектларына кертелгән гараж һәм машина урыны, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан, гараж һәм машина урыннары;»

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының

рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (https://pravo.tatarstan.ru).https://leninogorsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов